ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 11 » июль 2018 ел** **№ 597**

**Арча муниципаль район мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маенда кабул ителгән 413 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» карарын үтәү йөзеннән Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Арча муниципаль районы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәният-ял итү учреждениеләренең хезмәт хакы шартлары турында нигезләмә;

Арча муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә;

Арча муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә;

Арча муниципаль районының муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә;

2. Арча муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы әлеге карар нигезендә хезмәткә түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан шушы карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкән вакытка, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларының күләме сакланган һәм аларның шул ук квалификация эшләре башкарылган очракта, азрак була алмый дип билгеләргә.

3. Арча муниципаль районы мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле һөнәр берлекләре органы белән килештереп:

Арча муниципаль районы мәдәният учреждениеләре муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

Арча муниципаль районының муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә әлеге карар белән билгеләнгән хезмәткә түләү системасы кертелгәнчегә кадәр 2 айдан да соңга калмыйча хезмәт шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

4. 1 пункт 2018 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин